ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**29.10.2019**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 2285**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 2019нчы елның 4 нче апрелендәге 805нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 нче елның 22 нче октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законның 3 нче статьясындагы 17нче пунктына таянып, федераль законга туры килмәүне бетерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының архив бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 2019 нчы елның 4нче апрелендәге 805 нче номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. дәүләт һәм муниципаль милек рәвешендәге юридик затларга архивлар эшендә методик һәм практик ярдәм күрсәтү һәм эш башкаруда документлар оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентының 1.4 пунктындагы җиденче абзацын (карарның 3 нче кушымтасы) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«архив документларын тәртипкә салу - архив документларын саклау (эш) берәмлекләренә формалаштыру, архив эше һәм эш башкару өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә мондый саклау (эшләр) берәмлекләрен тасвирлау һәм рәсмиләштерү буенча эшләр комплексы»;

1.2. ликвидацияләнә торганн оешмаларның шәхси составы буенча документларны архив бүлегенә саклауга кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентының 1.5 пунктының дүртенче абзацын (Карарга 5 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«архив документларын тәртипкә салу - архив документларын саклау (эш) берәмлекләренә формалаштыру, архив эше һәм эш башкару өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә мондый саклау (эшләр) берәмлекләрен тасвирлау һәм рәсмиләштерү эшләре комплексы».

2. Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлек җитәкчесе Анисимов Д.С. бу карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәТатарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин